# КАРАР

**2023 елның 20 ноябре** **№31**

**Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә үзара салым акчалары кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылының Урман урамында 40 нче йорт янында үткәрергә.
2. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрү өчен территория чикләрен расларга: Кукмара районы Зур Кукмара авылы территориясенең Урман урамы чикләрендәге бер өлеше.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылының Урман урамында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 10500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

Зур Кукмара авылының Урман урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев